МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»

пр.Нефтяников, д.175, г.Елабуга, 423600

«АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

Нефтьчеләр пр., 175 нче йорт, Алабуга шәһәре, 423600

Тел.: (85557) 3-81-51, факс: (85557) 3-81-51, e-mail: Imc.Elb@tatar.ru, сайт: www.elabugaedu.ru

20.02.2020 № 183

На № _____ от _____

Татарстан республикасы Алабуга муниципаль районы
«10 нчы урта гомуми белем мәктәбе»
гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең
туган тел һәм әдәбият укытучысы
Фәсхиева Алисә Илфат кызының
педагогик хезмәтенә бәяләмә.

Фәсхиева Алисә Илфат кызы 2017 нче елда Казан Федераль университетының Алабуга институтын туган тел һәм әдәбият, инглиз теле укытучысы буларак; 2020 елда мәгариф оешмасы белән идарә итүче белгечлеге буенча тамамлады. Педагогик стажы — 3 ел. 2017нче елдан «10 нчы урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы булып эшли. Кыска гына вакыт эчендә ул үзен теоретик һәм методик яктан әзерлекле, укыту формаларын, метод һәм алымнарын сайлауга ижади якын килүче, яңалыкка омтылучы, балаларны, эшен яратучы оста мөгаллимә итеп танытты. Яшь белгеч үз эшчәнлегендә балаларның фикерләү сәләтен үстерүгә, танып-белу эшчәнлеген активлаштыруга, белем алуга омтылыш булдыруга, укучыларда коммуникатив, мәгьлумати-аналитик компетенцияләр формалаштыруга зур әһәмият бирә. Компьютер технологияларен, интернет сайтларын, онлайн-технологияләрне үзләштереп, аларны укучыларга белем биру максатында отышлы файдалана белүе аның интеллектуаль үсешкә ирешкән компетентлы белгеч икәнлеген күрсәтә. Укытучы дәресләрдә уен ситуацияләре кертә, парларда, төркемнәрдә эш алымнары ярдәмендә укучыларның коммуникатив, ижади мөстәкыйльлекләрен үстерү юнәлешендә эшли. Проблемалы сораулар, ситуацияләр аша йомшак үзләштерүче укучыларны да материал белән кызыксындыра, аңлы үзләштерүгә ирешә. Тырыш хезмәтенең нәтиҗәсе буларак, Алисә Илфат кызы укыткан сыйныфларда укучыларның белем сыйфаты югары: укытучы туган телдан 85%, әдәбияттан 90% сыйфатка, 100% өлгерешкә ирешә.

Алисә Илфат кызы һәрдаим үсештә. Ул, республикакүләм конкурста катнашып, 2017нче елда «Безнең яңа укытучыбыз» грантына ия булды. Агымдагы уку елында туган тел укытучыларының Бөтенрәсәй «Туган тел» мастер-класс бәйгесенец муниципаль этабында жиңүче булды. Укытучы үзенең һөнәри осталыгын арттыру өстендә даими эшли, конференцияләрдә, семинар-практикумнарда, вебинарларда катнаша. Осталык дәресләрендә, ачык дәресләрдә, туган тел һәм әдәбият укытучыларының муниципаль методик берләшмәсе утырышларында, укытучыларның август киңәшмәсендә үз эш стилен булдырган компетентлы белгеч булуын, оештыру осталыгын күрсәтә.

Сәләтле балаларны ачу һәм үстерү Алисә Илфат кызының педагогик эшчәнлегенең бер юнәлеше. Укытучы үзенең укучыларын фәнни һәм иҗади мөмкинлекләрен үстерүдә системалы эш алып бара. Тырышлыклары югары нәтиҗәләр күрсәтә (нәтиҗәләр таблицада күрсәтелгән). Тырыш хезмәте өчен А.И. Фәсхиева Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Укучыларның чыгышлары:

Чыгышлар исеме, елы	Нәтижә
Мероприятия посвященных ко Дню родного языка, Елабуга, 2019	участник
Открытый турнир интеллектуальной Лиги Мирах, Казань, 2019	2 место
Муниципальный этап республиканской олимпиады школьников по родному языку	победитель
Муниципальный конкурс «Габдулла Тукай шигырьләрен иң яхшы сөйләүче»	победитель
XIII Региональная научно-практическая конференция «Наше наследие»	Диплом I степени
Международный литературный конкурс «Джалиловские чтения»	участник

Укытучының уңышлары:

Чыгышлар исеме, елы	Нәтиҗә
Сертификации о профессиональной квалификации	диплом
Кадыйр Сибгатуллин исемендәге I региональ педагогик укулар	3 нче урын
XV Региональное педагогическое чтение имени Ризаэтдина Фахретддина	лауреат
Международный литературный конкурс «Джалиловские чтения»	диплом

Муниципальный этап республиканской олимпиады школьников по родному языку	Почетная группа
Мастер-класс на муниципальном обучающем семинаре «Образовательные технологии в контексте современного урока родного языка и литературы в условиях реализации ФГОС»	Сертификат
Литвинов исемендәге III региональ фәнни-гамәли конференция	2 нче урын

Фәсхиева А.И. педагогик эшчәнлеге һәм шәхси сыйфатлары белан башка укытучыларга үрнәк булып тора. Укытучының укучылар, ата-аналар, хезмәттәшләре белан мөнәсәбәте үзара ышаныч, бер-берсен хөрмәт итүгә нигезләнгән. Мөгаллимә югары сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә максатчан, нәтиҗәле эш алып бара, һарвакыт яңалыкка омтыла, интерактив технологияларне өйрәнә, уңышлы куллана.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Фәсхиева Алисә Илфат кызын Бөтенрәсәй «Туган тел» мастер-класс бәйгесендә катнашырга лаек дип табабыз.

“Алабуга муниципаль районы мәгариф идарәсе”муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Р.И.Зарипов**

Балобанова А.А
8855575258